СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗӘЙ-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

# РЕШЕНИЕ

2022 елның 19 декабре № 27

Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 30 маендагы 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 30 маендагы 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктта:

9 абзацны түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга «,шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштыру».»;

Түбәндәге эчтәлектәге 10 абзац белән тулыландырырга:

«Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлауларны һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында бердәм порталда урнаштыру Лениногорск муниципаль районының шәхси кабинетыннан файдаланып, белгеч, йә махсус төзелгән комиссияләр яки эш төркемнәре (алга таба – гавами тыңлауларны оештыручы) тарафыннан, Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты)

әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла,.»;

5.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5.4.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.4.1. Ачык тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Лениногорск муниципаль районы халкы тарафыннан, авторизациядән соң, бердәм портал кулланып, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм муниципаль норматив хокукый акт проектын билгеләү турында мәгълүмат басылып чыккан көннән башлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкы шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туган көне һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында мәгълүмат җибәрә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре кабул ителгән карарларны нигезләүне дә кертеп, ТР, Лениногорск районы, Зәй-Каратай авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырыла (халыкка игълан ителә), шулай ук Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (https://leninogorsk.tatarstan.ru) урнаштырыла һәм федераль дәүләт мәгълүмат системасы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең)» бердәм порталында, ачык тыңлаулар үткәрелгән көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла»;

16.5 пунктта «Районның рәсми сайтында» сүзләреннән соң «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны ТР, Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылы җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (https://leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе М.И.Идиятова